ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

__ _16.07.2026______________ № 535______

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга һәм бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары педагогларына бер мәртәбә түләнә торган түләү билгеләү турында нигезләмәне раслау хакында» 2026 елның 15 апрелендәге 332 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының бердәм дәүләт имтиханы (БДИ) нәтиҗәләре буенча 100 балл алган чыгарылыш укучыларын бүләкләү һәм укытучы һөнәренең абруен күтәрү һәм Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының бердәм дәүләт имтиханында 100 балл алган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләгән укытучыларын бүләкләү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга һәм бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган чыгарылыш сыйныф укучыларын әзерләгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары педагогларына бер мәртәбә түләнә торган түләү билгеләү турында нигезләмәне раслау хакында» 2026 елның 15 апрелендәге 332 номерлы карарына (30.06.2026 №498 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. 2026 елдан Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл алган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны 100 000 (йөз мең) сум күләмендә һәм бердәм

дәүләт имтиханында 100 балл алган чыгарылыш укучыларын әзерләгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укытучыларын бүләкләү өчен ел саен бер мәртәбә бирелә торган 149 500 (йөз кырык тугыз мең биш йөз) сум күләмендә (иминият кертемнәрен һәм физик затлар керемнәренә салымны исәпкә алып) түләү билгеләргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин